КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 октябрь г.Казань № 919

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 14 май, 383 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен

стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 14 май, 383 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 21 май, 415 нче, 2020 ел, 19 июнь, 505 нче, 2020 ел, 07 август, 661 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибендә:

2 пунктның икенче абзацында «2020 елның апрель – август айларында» сүзләрен «2020 елның апрель – сентябрь айларында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 елда хосусый медицина оешмаларына күрсәтелгән карар белән расланган яңа коронавируслы COVID-19 йогышы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

1.4 пунктта «2020 елның апреле – августы» сүзләрен «2020 елның апреле – сентябре» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның беренче абзацында «2020 елның 31 августы» сүзләрен «2020 елның 30 сентябре» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин